КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Республиканское агентство по печати
и массовым коммуникациям
Декабристов ул., 2, г.Казань, 420066

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
Республика матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066

Тел.: (843)570-31-22, факс:(843)537-91-04, ra.tatmedia@tatar.ru, tatmedia.tatarstan.ru

ПРИКАЗ БОЕРЫК

« 19 » октября 2023 г. № 187-п 2022 елның 19 октябре, № 187-п

Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләрен
иң яхшы яктыртуга республика
массакүләм мәгълүмат чаралары арасында
“Коррупциягә журналист карашы”
махсус журналистлар конкурсы үткәрү турында
Нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы карары белән расланган “2015 – 2025 елларга Татарстан Республикасы коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру турында” дәүләт программасын үтәү кысаларында боерык бирәм:

1. Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләрен иң яхшы яктыртуга республика массакүләм мәгълүмат чаралары арасында “Коррупциягә журналист карашы” махсус журналистлар конкурсы үткәрү турында кушымта итеп бирелә торган Нигезләмәне расларга.

2. “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының «Коррупцияне профилактикалау һәм аңа каршы көрәшү мәсьәләләрен Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга багышланган “Коррупциягә журналист карашы” конкурсын үткәрү турында» 2022 елның 29 июнендәге 101-п номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе урынбасары И.Ф.Миргалимовка йөкләргә.

Җитәкче А.С.Сәлимгәрәев

“Татмедиа” республика матбугат
һәм массакүләм коммуникацияләр
агентлыгының
2023 елның 19 октябрендәге
187-п номерлы боерыгы белән
РАСЛАНДЫ

**Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләрен
иң яхшы яктыртуга республика
массакүләм мәгълүмат чаралары арасында
“Коррупциягә журналист карашы”
махсус журналистлар конкурсы үткәрү турында
Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы карары белән расланган “2015 – 2025 елларга Татарстан Республикасы коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру турында” дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләрен иң яхшы яктыртуга республика массакүләм мәгълүмат чаралары арасында “Коррупциягә журналист карашы” махсус журналистлар конкурсын (алга таба – Конкурс) үткәрү тәртибен билгели.

1.2. Конкурсны оештыручы – “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы (алга таба – Оештыручы, Агентлык).

1.3. Конкурс ел саен 31 декабрьгә кадәр уздырыла.

Конкурс үткәрү турында мәгълүмат түбәндәге адрес буенча Агентлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырыла: https://www.tatmedia.tatarstan.ru («Яңалыклар» һәм «Конкурслар һәм проектлар» бүлекләрендә) (алга таба – Агентлыкның рәсми сайты). Конкурс үткәрү турындагы мәгълүматта Конкурс үткәрү шартлары, номинацияләр, махсус номинацияләрне дә кертеп, конкурс эшләрен бәяләү критерийлары һәм тәртибе, гаризалар кабул ителә башлау һәм тәмамлану урыны, сроклары, аларны тапшыру тәртибе, бүләкләр күләме һәм бүләкләү рәвеше, шулай ук Конкурс нәтиҗәләрен игълан итү тәртибе һәм сроклары күрсәтелә.

## 2. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

2.1.Конкурсның максаты – массакүләм мәгълүмат чаралары һәм җәмәгатьчелек игътибарын коррупция мәсьәләләренә җәлеп итү.

2.2. Конкурсның төп бурычлары:

- массакүләм мәгълүмат чараларында коррупция мәсьәләләрен яктыртуны стимуллаштыру;

- массакүләм мәгълүмат чараларында коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләрен яктырту;

- халыкка коррупция чагылышларына бәйле хәлләрнең тискәре нәтиҗәләре турында аңлату;

- коррупция чагылышларына бәйле хокук бозуларны профилактикалау буенча актив гражданлык позициясе булдыру;

- гражданнарда коррупциягә каршы һәм хокукый караш тәрбияләү;

- халыкта коррупциягә каршы гамәлгә ашырыла торган программаларның язмышы өчен җаваплылык хисе тәрбияләү, хакимияткә ышанычны ныгыту.

## 3. Конкурска гариза бирүчеләр һәм конкурста катнашучылар

3.1. Конкурста аерым журналистлар яисә Татарстан Республикасы территориясендә массакүләм мәгълүмат чаралары буларак теркәлгән редакцияләр (алга таба – ММЧ) катнаша ала.

Конкурска гариза бирүчеләр – Конкурс турында нигезләмәнең 4.7 пункты нигезендә документлар тапшырган аерым журналистлар яисә Татарстан Республикасы территориясендә массакүләм мәгълүмат чаралары буларак теркәлгән редакцияләр (алга таба – гариза бирүчеләр).

Конкурста катнашучылар – тапшырылган эшләре Конкурста катнашырга рөхсәт ителгән гариза тапшыручылар (алга таба – катнашучылар).

## 4. Конкурсны үткәрү шартлары

4.1. Конкурска бер генә гариза тапшырылса, яисә бер гариза да тапшырылмаса, Конкурс үткәрелмәгән дип санала.

4.2. Чишеп булмаслык проблемалар барлыкка килгәндә яисә финанслау булмаганда, Оештыручы конкурс эшләрен кабул итү өчен билгеләнгән срокны беренче яртысында конкурсны туктатырга мөмкин.

4.3. Конкурска массакүләм мәгълүмат чараларында Татарстан Республикасының ике дәүләт теленең берсендә дөнья күргән һәм алдагы Конкурска йомгак ясалган датадан алып чираттагы Конкурска гаризалар кабул итү тәгалләнү датасына кадәрге чорда эшләнгән материаллар кабул ителә.

4.4. Өченче затларның авторлык хокукларын үтәмәгән өчен җаваплылык эшләрне тәкъдим иткән катнашучыларга йөкләнә.

4.5. Конкурска түбәндәге конкурс эшләре төрләре кабул ителә:

MP4 форматында һәм (яисә) күчереп алу өчен актив сылтама белән CD- йә DVD-дискта, флешкартада кимендә 15 секундлык телевизион эшләр (программалар, махсус репортажлар, видеосюжетлар циклы һәм башка телевизион эшләр;

басма массакүләм мәгълүмат чараларындагы (газета-журналларда, альманахларда, башка басма массакүләм мәгълүмат чараларында) кимендә 500 басма тамгасы булган, төп нөсхәдә, ксерокс аша яки сканер аша чыгарылган

вариантта, юридик зат җитәкчесенең имзасы һәм мөһере белән таныкланган (булган очракта) яисә авторның имзасы куелган (физик затлар өчен) мәкаләләр (мәкаләләр сериясе, махсус чыгарылышлар);

кәгазь вариантта һәм (яисә) күчереп алу өчен актив сылтама белән CD- йә DVD-дискта, флешкартада «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә куелган язмалар;

MP4 форматында һәм (яисә) күчереп алу өчен актив сылтама белән CD- йә DVD-дискта, флешкартада кимендә 15 секундлык радио эшләр (программалар, махсус репортажлар, радиосюжетлар циклы).

4.6. Конкурска килгән эшләргә рецензия бирелми, алар кире кайтарылмый.

4.7. Конкурска түбәндәге документлар теркәлгән гариза кабул ителә::

а) әлеге Нигезләмәнең 4.3 һәм 4.5 пунктларына туры килә торган конкурс эшләре (3 – 10) (алга таба – конкурс эше);

б) Конкурста катнашу өчен әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта нигезендә анкета;

в) юридик зат буларак теркәлгән массакүләм мәгълүмат чарасы редакцияләре өчен:

юридик затны салым органында исәпкә кую турында таныклык (ИНН) (күчермәсе);

юридик зат җитәкчесен вазыйфага билгеләп кую турында боерык (күчермәсе);

гамәлгә кую документлары (күчермәләре);

ММЧ теркәү турында таныклык (күчермәсе);

г) аерым журналистлар, журналистлар коллективлары өчен:

шәхесне таныклаучы документ (күчермәсе);

әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта нигезендә Персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык бирү;

персональ белешмәләр субъекты рөхсәт иткән персональ белешмәләрне таратуга ризалык (3 нче кушымта нигезендә);

д) юридик зат булмаган массакүләм мәгълүмат чарасы редакцияләре өчен:

ММЧ теркәү турында таныклык (күчермәсе) йә теркәлгән массакүләм мәгълүмат чаралары реестрыннан өземтә;

баш мөхәррирне вазыйфага билгеләп кую турында боерык (күчермәсе);

массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе уставы яисә, массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясендә кимендә 10 кеше эшләсә, “Массакүләм мәгълүмат чаралары турында” 1991 елның 27 декабрендәге 2124-I номерлы Россия Федерациясе Законының (алга таба – ММЧ турында Закон) 20 статьясы нигезендә аны алмаштыра торган шартнамә.

Уртак эшләр тапшыра торган журналистлар коллективлары яисә массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре конкурс эшенә призлы урын бирелгән очракта акчаны процентлап бүлешү турында өстәмә рәвештә килешү тапшырырга тиеш.

Әлеге пунктның «б» – «д» пунктчаларында күрсәтелгән документлар кәгазь вариантта тапшырылган очракта оешма җитәкчесенең имзасы белән тамгалана һәм оешма мөһере (булган очракта) сугыла.

4.8. Гаризалар түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 420066, Татарстан

Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт, «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы, 6 кат, 604 нче кабинет, «Коррупциягә журналист карашы» дигән тамга белән. Телефон: 8 (843) 570-31-10, электрон почта адресы A.Smetanina@tatar.ru.

4.9. Документларның Агентлыкка килгән көне аларны тапшыру датасы дип санала.

4.10. Конкурста җиңүчеләрне бүләкләү турында Агентлыкның рәсми сайтында өстәмә рәвештә хәбәр ителә.

## 5. Конкурс номинацияләре

5.1. Конкурс түбәндәге номинацияләрдә үткәрелә:

«Вакытлы матбугат басмаларында коррупциягә каршы иң яхшы язмалар сериясе»;

«Коррупциягә каршы иң яхшы телесюжетлар сериясе»;

«Коррупциягә каршы иң яхшы радиосюжетлар сериясе»;

«Интернет басмаларда коррупциягә каршы иң яхшы язмалар сериясе»;

«Коррупциягә каршы тематиканы Интернетта социаль челтәрләрдә иҗади чагылдыру» (социаль номинация);

«Коррупциягә каршы иң яхшы журналист тикшеренүе» (махсус бүләк).

## 6. Финанслау

6.1. Конкурсны оештыруга һәм үткәрүгә бәйле чыгымнар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы карары белән расланган “2015 – 2025 елларга Татарстан Республикасы коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру турында” дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында конкурс үткәрү өчен агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында каралган акчалар исәбеннән тотыла.

6.2. Гомуми приз фонды 525,0 сум тәшкил итә.

6.3. Конкурста җиңүчеләр дипломнар һәм акчалата премияләр белән түбәндәге тәртиптә бүләкләнә:

**«Вакытлы матбугат басмаларында коррупциягә каршы иң яхшы язмалар сериясе»:**

1 урын – 45,0 мең сум (I дәрәҗә Диплом);

2 урын – 35,0 мең сум (II дәрәҗә Диплом);

3 урын – 25,0 мең сум (III дәрәҗә Диплом).

**«Коррупциягә каршы иң яхшы телесюжетлар сериясе»:**

1 урын – 45,0 мең сум (I дәрәҗә Диплом);

2 урын – 35,0 мең сум (II дәрәҗә Диплом);

3 урын – 25,0 мең сум (III дәрәҗә Диплом).

**«Коррупциягә каршы иң яхшы радиосюжетлар сериясе»:**
1 урын – 45,0 мең сум (I дәрәҗә Диплом);
2 урын – 35,0 мең сум (II дәрәҗә Диплом);
3 урын – 25,0 мең сум (III дәрәҗә Диплом).

**«Интернет басмаларда коррупциягә каршы иң яхшы язмалар сериясе»:**
1 урын – 50,0 мең сум (I дәрәҗә Диплом);
2 урын – 40,0 мең сум (II дәрәҗә Диплом);
3 урын – 30,0 мең сум (III дәрәҗә Диплом).

**«Коррупциягә каршы тематиканы Интернетта социаль челтәрләрдә иҗади чагылдыру» –** 50,0 мең сум **(**Диплом).

**«Коррупциягә каршы иң яхшы журналист тикшеренүе»** – 55,0 мең сум (Диплом).

6.4. Юридик затларга акчалата премияләр Конкурс йомгаклары турында беркетмәгә имза салган мизгелдән алып 20 көн дәвамында, җиңүчеләрне игълан иткәннән соң, Агентлык җитәкчелегенә язылган рәсми хатта күрсәтелгән исәп-хисап счетына күчерү юлы белән түләнә.

6.5. Физик затларга акчалата премияләр Конкурс йомгаклары турында беркетмәгә имза салган мизгелдән алып 20 көн дәвамында, җиңүчеләрне игълан иткәннән соң, Агентлык җитәкчелегенә язылган рәсми хатта күрсәтелгән исәп-хисап счетына күчерү юлы белән түләнә.

## 7. Конкурс эшләрен Конкурста катнашырга рөхсәт итү критерийлары

7.1. Оештыручы гаризаны алган көннән алып өч эш көне дәвамында, конкурс эшләренең әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен бәяләү нәтиҗәләре буенча, Конкурста катнашырга рөхсәт итү яисә  рөхсәт итмәү турында карар кабул итә.

Конкурста катнашуга рөхсәт бирмәү өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

гаризаның әлеге Нигезләмәнең 4.3, 4.5., 4.7. пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә  гаризага әлеге Нигезләмәнең 4.7. пунктында каралган документларны теркәмәү;

сурәтендә яисә тавышында хилафлыклар булган эшләр тәкъдим итү;

гаризаны билгеләнгән срокны  бозып тапшыру;

гариза бирүче «Чит илләр йогынтысында булган затларның эшчәнлеген тикшереп тору турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты статусына ия.

7.2.  Гариза бирүчегә Конкурста катнашырга рөхсәт итү яисә рөхсәт итмәү турында хәбәр карар кабул ителгәннән алып бер эш көне дәвамында Оештыручы җитәкчесе имзалаган һәм анкетада күрсәтелгән адреска җибәрелгән заказлы хат белән хәбәр ителә.

7.3. Конкурска кертелмәгән эшләр, гариза тапшыруның Оештыручының рәсми сайтында күрсәтелгән срогында, кимчелекләре төзәтелеп, яңадан тәкъдим ителергә мөмкин.

## 8. Конкурс эшләрен бәяләү критерийлары

8.1. Конкурс эшләрен бәяләү критерийлары:

теманың ачылышы (0 – 10 балл);

материалларның актуаль һәм үтемле булуы (материалның мөһимлеге, әһәмиятле булуы, файдаланылган ресурслар һәм нәтиҗә чагыштырмасы) (0 – 10 балл);

авторның (авторларның) һөнәрилеге, аналитика (0 – 10 балл);

теманы яктыртуның кабатланмаган булуы, иҗади алымнар (0 – 10 балл).

## 9. Конкурс комиссиясен оештыру һәм аның эшчәнлек тәртибе

9.1. Конкурс комиссиясе составы Оештыручы боерыгы белән раслана һәм комиссия рәисеннән, рәис урынбасарыннан һәм әгъзалардан тора.

9.2. Конкурс комиссиясе үз эшен түләүсез нигездә башкара.

9.3. Конкурс комиссиясенең эше утырышта башкарыла. Утырыш, әгәр анда әгъзаларның яртысыннан артыгы катнашса, тулы хокуклы дип санала.

9.4. Конкурс комиссиясе эшенә рәис җитәкчелек итә. Комиссия рәисе булмаганда, рәис вазыйфалары конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан билгеләнә торган урынбасарга йөкләнә.

9.5. Конкурс комиссиясе әгъзалары конкурс эшләрен әлеге Нигезләмәнең 8 бүлегендә күрсәтелгән критерийлар нигезендә бәяли. Һәрбер критерий буенча баллар саны 10-баллы шкала буенча бәяләнә (0 – 10 балл).

Һәрбер гариза буенча гомуми балл конкурс комиссиясенең барлык әгъзалары бәясен исәпкә алып билгеләнә.

Һәрбер гариза буенча гомуми балларны чагыштырып, конкурс комиссиясе балларның кими баруы тәртибендә катнашучыларның рейтингын төзи.

Гомуми балларның кими баруы тәртибендә рейтингта беренче өч урынны алган катнашучылар номинациядә 1, 2, 3 урын алган җиңүчеләр дип таныла.

Иң күп балл җыйган катнашучы махсус номинациядә җиңүче булып таныла.

9.6. Баллар саны тигез булганда, конкурс комиссиясе призлы урынны ике яки күбрәк катнашучыга бирергә мөмкин. Бу очракта Оештыручы премияләр өчен тәгаенләнгән акчаларны бу катнашучылар арасында тигез өлешләрдә бүлеп бирә.

9.7. Номинацияләрнең берсенә бер генә гариза бирелсә яки бер гариза да бирелмәсә, йә бер генә гариза да конкурс шартларына туры килмәсә, шулай ук номинациядә җиңүче билгеләнмәгән очракта, әлеге номинациядә конкурс үтмәгән дип таныла һәм акчалар башка номинацияләрдә билгеләнгән җиңүчеләргә тигез өлешләрдә бүленә.

9.8. Җиңгән эш берничә авторныкы (физик затлар өчен)/берничә ММЧ (юридик затлар өчен) булса, ул эшне башкаруда катнашкан затлар арасында үзләре килешенгән күләмдә бүленә. Мондый килешү документлар белән бергә тапшырыла.

9.9. Оештыру-техник эшчәнлекне координацияләү, утырышларны әзерләү һәм документларны алып бару өчен Конкурсны оештыручы җаваплы секретарь билгели.

9.10. Җаваплы секретарь конкурс комиссиясе составына керми.

9.11. Конкурс комиссиясе утырышы уздырылган көннән алып биш эш көне эчендә Конкурс комиссиясе утырышы йомгаклары буенча беркетмә рәсмиләштерелә, аңа утырышта булган конкурс комиссиясе әгъзаларының имзасы салына, беркетмә конкурс комиссиясе рәисе яисә рәисе урынбасары тарафыннан раслана.

9.12. Конкурс йомгаклары турында мәгълүмат беркетмәгә кул куелганнан соң өч календарь көн эчендә Агентлыкның рәсми сайтына урнаштырыла.

## 10. Аерым шартлар

10.1. Оештыручылар түбәндәгеләргә хокуклы:

әлеге Нигезләмәдә һәм Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында билгеләнгән очраклардан, шулай ук бәхәсле очраклардан тыш, Конкурста катнашучылар белән язмача йә башка төрле элемтәләргә кермәскә;

эшләрне тапшыру срогының беренче яртысында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп, Конкурсны туктатырга яки әлеге Нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә, бу хакта Оештыручыларның рәсми сайтында тиешле мәгълүмат урнаштырып, Катнашучыларга хәбәр итәргә.

10.2. Конкурс шартлары үзгәрү турында хәбәрнамә алганнан соң, Конкурста катнашучы эшләрне элек билгеләнгән шартларда кабул итүне яисә кертелгән үзгәрешләрне гамәлдә түгел дип тануны таләп итә алмый. Аның эшне Конкурсның яңа шартларына туры китереп үзгәртүе алга таба конкурста катнашырга мөмкинлек бирә.

Коррупциягә каршы көрәшү мәсьәләләрен
иң яхшы яктыртуга республика
массакүләм мәгълүмат чаралары арасында
“Коррупциягә журналист карашы”
махсус журналистлар конкурсы турында
нигезләмәгә
1 нче кушымта

Коррупциягә каршы көрәшү мәсьәләләрен иң яхшы яктыртуга республика массакүләм мәгълүмат чаралары арасында “Коррупциягә журналист карашы” махсус журналистлар конкурсында катнашу өчен

АНКЕТА

Гариза бирүче

______________________________________________________________

Телефоны _______________________________________________

Материалның чыгу датасы

________________________________________________________________

Номинация исеме

___________________________________________________________

Конкурска тапшырыла торган эшнең исеме

____________________________________________________________

Кыскача эчтәлеге

_________________________________________________________________

_________________________________________________________________

_________________________________________________________________

Адрес

_____________________________________________________________

Телефон/факс

______________________________________________________

e-mail

_____________________________________________________________

Эшләрне сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлдерелгән социаль реклама конкурсына тәкъдим итү өченче затларның авторлык хокукын яисә башка хокукларын бозмый.

ММЧ редакциясе җитәкчесе (журналист) исем-фамилиясе, атасының исеме_____________________________________________________________

(җитәкче/ физик зат  имзасы, мөһер (булган очракта)

*Атасының исеме булган очракта күрсәтелә

Коррупциягә каршы көрәшү мәсьәләләрен
иң яхшы яктыртуга республика
массакүләм мәгълүмат чаралары арасында
“Коррупциягә журналист карашы”
махсус журналистлар конкурсы турында
нигезләмәгә
2 нче кушымта

(Тәкъдим ителә торган форма)

**Персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык**

Мин,________________________________________________________________,
яшәү адресым__________________________________________
_______________________________________________________________,
шәхесне таныклаучы төп документым (паспорт)____________________
__________________________________________________________________
______________________________, “Персональ белешмәләр турында” 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (алга таба – оператор) (адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 йорт) коррупциягә каршы көрәшү мәсьәләләрен иң яхшы яктыртуга республика массакүләм мәгълүмат чаралары арасында “Коррупциягә журналист карашы” махсус журналистлар конкурсында катнашуга бәйле рәвештә үземнең персональ белешмәләрне эшкәртүгә, аларны җыюны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, төгәлләштерүне (яңартуны, үзгәртүне), алардан файдалануны, аларны таратуны (шул исәптән башкаларга тапшыруны), үз исемемнән башка файдалануны, блокировать итүне, юкка чыгаруны да кертеп, ризалыгымны бирәм.

Эшкәртүгә ризалыгымны бирә торган персональ белешмәләрнең исемлеге:

| | |
|---|---|
| Эшкәртүгә ризалыгымны бирә торган персональ белешмәләрнең исемлеге: | (фамилия, исем, атасы исеме, җенес, туган көн һәм урын, гражданлык, шәхесне таныклаучы документның реквизитлары (документ төре, сериясе һәм номеры, кем тарафыннан бирелүе), яшәү урыны, теркәлү урыны, телефон номеры (шул исәптән кәрәзле телефон), электрон почта адресы, Россия Федерациясе кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счеты турында белешмәләр) |

Әлеге ризалык имзаланган көннән алып 1 (бер) ел гамәлдә була.

Персональ белешмәләрнең субъекты үз персональ белешмәләрен эшкәртүгә әлеге ризалыкны, бу хакта операторга язмача хәбәр итеп, кире алырга хокуклы.

Персональ белешмәләрнең субъекты үз персональ белешмәләрен эшкәртүгә әлеге ризалыкны кире алган очракта оператор аларны эшкәртүне туктатырга яисә туктатуны тәэмин итәргә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) һәм, персональ белешмәләрне эшкәртү өчен аларны саклау башкача кирәк булмаса, ризалыкны кире алу турында мөрәҗәгать кергән көннән алып утыз көн эчендә персональ белешмәләрне юкка чыгарырга яисә юкка чыгаруны тәэмин итәргә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) тиеш. Күрсәтелгән вакыт эчендә персональ белешмәләрне юкка чыгару мөмкинлеге булмаган очракта, оператор аларны блокировать итә яисә блокировать итүне тәэмин итә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) һәм персональ белешмәләрне иң күп дигәндә алты ай эчендә юкка чыгара.

_______________________________________________________________/______________

(персональ белешмәләр субъектының Ф.И.Ат ис. (булган очракта күрсәтелә) һәм имзасы)

_______________

(Дата)

---

*Атасының исеме булган очракта күрсәтелә

Коррупциягә каршы көрәшү мәсьәләләрен
иң яхшы яктыртуга республика
массакүләм мәгълүмат чаралары арасында
“Коррупциягә  журналист карашы”
махсус журналистлар конкурсы турында
нигезләмәгә
3 нче кушымта

(Тәкъдим ителә торган форма)

**Тарату өчен персональ белешмәләр субъекты тарафыннан рөхсәт ителгән персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык**

Мин, ___________________________________________________________________,
(фамилия, исем, атасының исеме (булган очракта) рус телендә)
_______________________________________________________________________,
(почта адресы)
_______________________________________________________________________,
(электрон почта адресы)
_______________________________________________________________________,
(телефон номеры)
“Персональ белешмәләр турында” 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның $10^1$ статьясы нигезендә “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (ОГРН 1031621014765, ОКТМО 92701000, ОКПО 14912163) юридик адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 йорт) коррупциягә каршы көрәшү мәсьәләләрен иң яхшы яктыртуга республика массакүләм мәгълүмат чаралары арасында “Коррупциягә журналист карашы” махсус журналистлар конкурсында катнашуга бәйле рәвештә үземнең персональ белешмәләрне таратуга (шул исәптән башкаларга тапшыруга, бирүгә) ризалыгымны бирәм.

Эшкәртүгә ризалык бирелә торган персональ белешмәләрнең категориясе һәм исемлеге

| N т/с | Персональ белешмәләр | Ризалык | |
|---|---|---|---|
| | | Әйе | ЮК |
| Гомуми персональ белешмәләр | | | |
| | Фамилия | | |
| | Исем | | |
| | Атасы исеме (булган очракта) | | |
| | Туган ел, ай, дата һәм урын | | |
| | Шәхесне таныклаучы документның реквизитлары (төре, сериясе, датасы, кем тарафыннан бирелүе) | | |
| | Яшәү урыны, теркәлү урыны | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Телефон | | |
| | Электрон почта адресы | | |
| | Банк реквизитлары | | |

Эшкәртү өчен шартлар һәм тыю билгеләнә торган персональ белешмәләрнең категориясе һәм исемлеге

| N т/с | Персональ белешмәләр | Билгеләнә торган шартлар һәм тыюлар исемлеге |
|---|---|---|
| 1. [Персональ белешмәләрнең категориясе] | | |
| | [Персональ белешмәләрнең исемлеге] | |

Искәрмә. Күрсәтелгән таблица персональ белешмәләр субъектының теләге буенча, персональ белешмәләрне эшкәртүне гамәлгә ашыра торган оператор тарафыннан чикләүләрсез тутырыла.
Шартлар һәм тыюлар операторның чикләнмәгән яисә кайбер даирә затларына әлеге персональ белешмәләрне таратуга һәм (яисә) тапшыруга бәйле гамәлләрен чикләүне йә тыюны күздә тота.
Ризалыкта өстәмә шартлар да күрсәтелергә мөмкин, алар алынган персональ белешмәләрне эшкәртүне гамәлгә ашыра торган оператор тарафыннан мәгълүмат кайбер хезмәткәрләргә генә җиткерелә торган эчке элементәләр буенча йә мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша тапшыруны, яки алынган персональ белешмәләрне тапшырмауны күздә тота

Операторның персональ белешмәләр субъектының персональ белешмәләре чикләнмәгән яисә кайбер даирә затларына тапшырылырга мөмкин мәгълүмат ресурслары турында белешмәләр: http://tatmedia.tatarstan.ru/.

Әлеге ризалык _____________________________ срокта гамәлдә була.

**(ризалыкның гамәлдә булу срогы)**

Персональ белешмәләр субъекты, операторга язмача хәбәр итеп, үзенең персональ белешмәләрен эшкәртүгә бирелгән ризалыктан баш тартырга хокуклы.
Персональ белешмәләр субъекты, операторга язмача хәбәр итеп, үзенең персональ белешмәләрен эшкәртүгә бирелгән ризалыктан баш тарткан очракта оператор мондый баш тартуны алган көннән алып иң күбе утыз көн эчендә аларны эшкәртүне туктатырга яисә туктатуны тәэмин итәргә (әгәр бу эш оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарылса) һәм, элек куелган максатлар өчен персональ белешмәләрне эшкәртү башкача таләп ителмәсә, персональ белешмәләрне юкка чыгарырга яисә юкка чыгаруны тәэмин итәргә (әгәр бу эш оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарылса) тиеш.
Күрсәтелгән срокта персональ белешмәләрне юкка чыгару мөмкинлеге булмаган очракта, оператор мондый персональ белешмәләрне блокировать итә яисә блокировать итүне тәэмин итә (әгәр бу эш оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарылса) һәм персональ белешмәләрне алты айдан артмаган срокта юкка чыгаруны тәэмин итә.

______________(персональ белешмәләр субъекты имзасы)

______________ (число, ай, ел)